


Июль аенда Халыкара шахмат конен билгеләп vттек. Шахмат - хәзерге донья шартларында шәхес vсешенен кирәкле коралы. Уен тормышта файдалы кv-некмәләр бирә: стратегик һәм тактик фикерләvне vстерә, логика һәм игътибар нигезләрен сала, акыл сәләтен ача. Шахмат уены - 64 аклы-каралы шакмактан торган тактада барган, игътибарлылык, уйлау сәләтен таләп итvче спорт торе дә, уен да ул!

Шахмат уены тарихына да игътибар итик. Шахмат уены барлыкка килгәнче, Һиндстанда чатуранга дигән уен була. Урта гасырларда бу уен белән гарәпләр кызыксына. Аннары Испания аша ботен Европага тарала. Россиядә шахмат IX-X гасырларда барлыкка килгән. Шул дәвердән ул интеллектуаллар арасында зур популярлык казана. Бәйрәм итә торган конне торле дә-рәжәдә шахмат ярышлары, Шахмат клуб-ларында шахмат турнирлары, мастер-класслар vткәрелә. Ин яхшы уенчылар бvләкләр һәм призлар ала. Ковылкино шәһәрендә Халыкара шахмат коненә багышлап, шахмат турниры vткән. Анда кvп тапкырлы район һәм республикабыз турнирлары жинvчесе һәм призеры Искандәр Саид улы Эртуганов катнаша һәм ярышнын жинvчесе дә була. Ул (фотода кызы Адилә белән) бvген Торбеево поселогында яши һәм ООО «Газпром трансгаз Нижний Новгород» - Торбеевское ЛПУ МГ филиалында хезмәт итә. Әйтеп китәргә кирәк, бу предприятие житәкчеләре спортнын торле торләренә зур игътибар бирә һәм хезмәткәрләре матур нәтижәләр кvрсәтәләр.

Язма героебыз белән якыннан танышыйк. Искандәр Саид улы Эртуганов 1975 елда Торбеево районы яраткан шагыйре, бу авылны бар доньяга таныткан Һади Такташнын Сыркыдысында туган. Ул якташы ижатын белә һәм анын белән горурланып яши.




Торбеевское ЛПУ МГ